Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 ноябрь 2021 ел № 89

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11маендагы 233 номерлы «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисе, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 1 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 04 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисе, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 30 сентябрендәге 323 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисе, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибендә һәм шартларында:

1) I бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлмәт муниципаль районы башлыгы, башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторының айлык

акчалата бүләкләү размеры әлеге карарга 3 нче кушымтада күрсәтелгәннән артык булмаган күләмнәрдә билгеләнә.»;

2) I бүлекнең 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлмәт муниципаль районы башлыгы, башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторының еллык түләүле отпуск бирелгәндә бер мәртәбә бирелә торган түләү айлык акчалата түләүнең бер күләменнән артып китмәгән күләмдә түләнә.»;

3) I бүлекнең 6 пунктында «1,07 күләмендә» сүзләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «0,62 күләмендә»;

4) I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6.1 пункт өстәргә:

«6.1. Әлмәт муниципаль районының Контроль-хисап палатасы аудиторына, еллык түләүле отпуск биргәндә айлык акчалата түләү һәм бер мәртәбә түләүдән тыш, ай саен 0,62 айлык акчалата бүләкләү күләмендә акчалата бүләкләү түләнә.

Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы аудиторына эш нәтиҗәләре буенча өстәмә премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актларда каралган башка түләүләр башкарылырга мөмкин, эш бирүче карары белән муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен үтәүне исәпкә алып.»;

1.2 Карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:
«Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 34494 |
| Район Советы Аппараты җитәкчесе | 31850 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 31275 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 31160 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 28286 |
| Идарә башлыгы, мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 23686 |
| Идарә башлыгы урынбасары, мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 19547 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, район башлыгы киңәшчесе, Башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 19547 |
| Башкарма комитет идарәсе составында бүлек җитәкчесе | 19547 |
| Бүлек мөдире | 18167 |
| Баш белгеч | 17477 |
| Әйдәп баручы белгеч | 16443 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 14718 |

1.3. карарга 3 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә
Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, Әлмәт муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисенә айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләме |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Башлык | 34967 |
| Башлык урынбасары | 31469 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 31469 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 28286 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 23686» |

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар (Грушин А.И.), законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә (Парфилова Н.В.) буенча даими комиссияләренә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов